КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 22 июнь г.Казань № 412

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә катнаш эшкәртү режимында җитештерелә торган җылылык энергиясе җибәрүче «Таттеплосбыт» ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин ителә торган торак урыннарда яшәүче гражданнарга һәм «ТГК Уруссинская ГРЭС» ябык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин ителә торган торак урыннарда яшәүче Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы гражданнарына торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләве артуны киметүгә максатчан субсидия бирү турында» 2012 ел, 27 август, 738 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 19 ноябрь, 1013 нче, 2014 ел, 26 февраль, 122 нче, 2016 ел, 12 май, 299 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге карарның көче 2012 елның 1 сентябреннән 2017 елның 30 июненә кадәр максатчан субсидия алучы булмаган гражданнарга кагылмый.»;

әлеге карар белән расланган Гражданнарның торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләве артуны киметүгә максатчан субсидия турындагы нигезләмәдә:

2.1 пункттагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Төркем | Бер гаилә әгъзасына керем зурлыгы | К |
|---|---|---|
| I | 10 000 сумга кадәр | 1 |
| II | 10 001 сумнан 20 000 сумга кадәр | 0,75 |
| III | 20 001 сумнан һәм югарырак | 0». |

2. Әлеге карар 2017 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\412.docx